**«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**
**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Башлыгының 2023 елның 13 ноябрендәге 121 номерлы карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 24 ноябренә 09 сәгать 00 минутка **Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 24 ноябренә 10 сәгать 00 минутка **Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2023 елның 24 ноябренә 11 сәгать 00 минутка **Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. 2023 елның 24 ноябренә 13 сәгать 00 минутка **Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

5. 2023 елның 24 ноябренә 14 сәгать 00 минутка **Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

6. 2023 елның 24 ноябренә 15 сәгать 00 минутка **Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

7. Халык җыенын үткәрү өчен, яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.
8. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләр  кала, Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге **Зур Кукмара** торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

1. Юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

2. Вак таш түшәп, чокырларны төзекләндерү.

3. Зур Кукмара авылының урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

4. Зур Кукмара авылында чишмәләр территориясен төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү.

5. Урамнарны яктырту өчен, энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру.

6. Балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

7. Су суырту башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су суырту башняларын ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, артезиан скважиналарын ремонтлау.

8. Зур Кукмара авылында Нурминкә елгасы аша Эшчеләр, М. Җәлил, Вахит, Октябрь, Колхоз, Х. Туфан, Елга аръягы урамнарына җәяүлеләр күперен төзекләндерү.

9. Яр буе зонасын карап тоту, мәчеттән алып Зур Кукмара стадионына кадәр җәяүлеләр күперен яшелләндерү һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү.

10. Зур Кукмара авылында җәяүлеләр күперен төзү, проект документларын эшләү.

11. Зур Кукмара авылындагы «Быргы» чишмәсенә бара торган җәяүлеләр тротуарын төзекләндерү.

12. Зур Кукмара авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

13. Зур Кукмара авылы һәйкәлен төзү, ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документациясен эшләү.

14. Зур Кукмара авылында тукталыш павильоннарын буяу очен буяулар сатып алу, проект-смета документларын эшләү.

15. Янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, янгын гидрантларын комплектлау, проект-смета документларын эшләү.

16. Ял зоналарын булдыру һәм төзекләндерү буенча чаралар үткәрү; Сабантуй бәйрәме уздыру урыны территориясен төзү һәм төзекләндерү.

17. Зур Кукмара стадионын яктырту алу һәм урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту.

18. Зур Кукмара авылында эскәмияләр һәм спорт инвентарьлары сатып алу, урнаштыру.

19. Яңа сүүткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү

20. Халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү

21. Зур Кукмара авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

9. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Зур Кукмара авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

10. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегенең «Кукмара ш. МБ " бүлекчәсендә урнаштыру юлы белән кабул ителгән соң 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

11. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы Р. Р. Хәнәфиев